РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«30» декабрь 2019 ел г. Альметьевск № 2312

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Башкарма комитетының
«2019 елга Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районында
социаль юнәлешле коммерциягә
карамаган оешмаларга ярдәм итү»
муниципаль программасын раслау турында»
2019 елның 17 маендагы 955 номерлы
карарына үзгәреш кертү хакында

Финанслауны төгәлләштерүгә бәйле рәвештә,

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «2019 елга Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм итү» муниципаль программасын раслау турында» 2019 елның 17 маендагы 955 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары» программасы паспортының 8 пунктына 1 250 мең сумны 250 мең сумга алмаштырырга;

1.2. Программа паспортының 5 бүлеген яңа редакциядә бәян итәргә:

«Чараларны финанслау Әлмәт муниципаль районы бюджеты акчалары хисабына башкарыла. Программаны гамәлгә ашыруга тотыла торган акчалар күләме Әлмәт муниципаль районы бюджеты мөмкинлекләреннән чыгып ачыкланырга һәм төзәтмәләр кертергә мөмкин. Тәкъдим ителгән программаны гамәлгә ашыру өчен җирле бюджеттан 250 мең сум акча планлаштырылган.»;

1.3. Муниципаль программага кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә:

ПРОГРАММА ЧАРАЛАРЫ ИСЕМЛЕГЕ:

Зак. № 305-2000

| № п/п | Чаралар исеме | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторы, үлчәү берәмлекләре | Башкаручы | Индикаторлар әһәмияте | Индикаторлар әһәмияте | Район бюджеты чыгымнары суммасы (мең сум) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2018 | 2019 | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 1 | СО НКОның конкурс документларын рәсмиләштерү мәсьәләләрендә консультация ярдәме күрсәтү | консультация саны | Балалар һәм яшьләр эшләре идарәсе; «Вертикаль» социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм күрсәтү ресурс үзәге» АНО | 45 | 70 | 0,0 |
| 2 | Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм итү буенча федераль һәм региональ конкурсларда катнашу өчен проект гаризаларын формалаштыру мәсьәләсе буенча озата бару | гариза бирүчеләр саны | Балалар һәм яшьләр эшләре идарәсе; «Вертикаль» социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм күрсәтү ресурс үзәге» АНО | 26 | 35 | 0,0 |
| 3 | Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар вәкилләре катнашында гомумшәһәр чаралары һәм акцияләр үткәрү | кеше саны | Балалар һәм яшьләр эшләре идарәсе; Мәгариф идарәсе; Социаль яклау идарәсе | 2000 | 3000 | 0,0 |
| 4 | СО НКОның эшчәнлеге турында мәгълүматны район сайтында һәм СМИда урнаштыру | мәкаләләр саны | Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара эшчәнлек бүлеге | 12 | 20 | 0,0 |